| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 30.05.2017 № 246-пр

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында вазифага билгеләгәндә конкурс үткәрелми ала торган, эш вазифаларын башкару дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматны куллануга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында**

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясының 3 өлешенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге № 63 Карары белән расланган Россия Федерациясе вазифаи затларын һәм гражданнарны дәүләт серенә керергә хокук алу тәртибе турында инструкциясенә таянып, боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында вазифага билгеләгәндә конкурс үткәрелми ала торган, эш вазифаларын башкару дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматны куллануга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының тәкъдим ителгән исемлеген раcларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында вазифага билгеләгәндә дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрелми торган, эш вазифаларын башкару дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматны куллануга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының тәкъдим ителгән исемлеген раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 03.03.2011, № 64 боерыгын;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында вазифага билгеләгәндә дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрелми торган, эш вазифаларын башкару дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматны куллануга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының тәкъдим ителгән исемлеген раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре

министрлыгында 03.03.2011, № 64 боерыгына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 25.05.2011 № 201-пр боерыгын.

3. Хокук идарәсенә (Воронина Е.А.) әлеге Боерыкны дәүләт регистрациясенә юлларга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
30 май 2017 ел № 246-пр
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында вазифага билгеләгәндә конкурс үткәрелми ала торган, эш вазифаларын башкару дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматны куллануга бәйле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

1. Министрның беренче урынбасары

2. Министр урынбасары

3. Эшләр идарәчесе

4. Хокук идарәсе башлыгы

5. Җир ресурслары идарәсе башлыгы

6. Мөлкәт идарәсе башлыгы

7. Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати арадашлык идарәсе башлыгы

8. Аренда, дәүләт мөлкәтен реализацияләү һәм инвестицияләр проектлары бүлеге мөдире

9. Кадрлар бүлеге мөдире

10. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте реестры бүлеге мөдире

11. Финанслар һәм дәүләт заказы бүлеге мөдире

12. Икътисад бүлеге мөдире

13. Яшерен режимлы хезмәтнең әйдәп баручы киңәшчесе